# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару методикасы**

I-муниципаль районы (шәһәр округы) өчен субвенцияләрнең планлаштырыла торган күләме бер тапкыр юл йөрү исәбеннән гомуми файдаланудагы шәһәр транспортында пассажирлар йөртүнең уртача тарифыннан, бер айда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталар) буенча исәпләүгә кабул ителә торган юл йөрүләрнең айлык уртача санынннан, бер айга исәпләгәндә сатылган бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарның) уртача саныннан һәм бердәй айлык социаль юл йөрү билетының һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетының билгеләнгән хакыннан (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарны тутыру хакыннан) чыгып билгеләнә.

Субвенция күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = (Т_{ср.} \times П_{ср.} - Ц_{в}) \times Р_{в} \times 12 \text{ ай} + (Т_{ср.} \times П_{ср.} - Ц_{д}) \times Р_{д} \times 12 \text{ ай},$$

монда:

$C_i$ – i-муниципаль районына (шәһәр округына) бүлеп бирелә торган субвенция күләме;

$Т_{ср.}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) бер тапкыр юл йөрү исәбеннән гомуми файдаланудагы шәһәр транспортында пассажирлар йөртүнең уртача тарифы.

Юл йөрү өчен өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта белән түләгәндә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тарифлар буенча бәяләрне дәүләт җайга салуы өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан 50 тапкыр һәм аннан күбрәк юл йөрүгә озак вакытлы файдаланудагы билетлар белән юл йөрүне түләү өчен билгеләнгән гамәлдәге тарифлардан чыгып исәпләнгән гомуми файдаланудагы шәһәр транспортында пассажирлар йөртүнең уртача тарифы кулланыла;

$П_{ср.}$ – узган ел белешмәләре нигезендә бер айда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты яки балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта) буенча юл йөрүләрнең айлык уртача саны.

I-муниципаль районында (шәһәр округында) юл йөрүләрнең саны автоматлаштырылган рәвештә исәпләп барылганда, өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта буенча юл йөрүләрнең уртача саны юл йөрү өчен

автоматлаштырылган түләү системасы операторларының узган ел белешмәләреннән чыгып алына.

I-муниципаль районында (шәһәр округында) юл йөрүләрнең саны автоматлаштырылган рәвештә исәпләп барылмаганда, бердәй айлык социаль юл йөрү билеты яисә балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты буенча юл йөрүләрнең уртача саны 50 тапкыр юл йөрүгә тигез итеп алына;

$Ц_{в}$ – бердәй айлык социаль юл йөрү билетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән хакы;

$Ц_{д}$ – балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән хакы;

$Р_{в}$ – і-муниципаль районында (шәһәр округында) бер айга исәпләгәндә сатылган бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының (өстәмә транспорт ташламасы булган тутырылган электрон карталарның) уртача саны;

$Р_{д}$ – і-муниципаль районында (шәһәр округында) бер айга исәпләгәндә балалар өчен сатылган бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының (өстәмә транспорт ташламасы булган тутырылган электрон карталарның) уртача саны.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2012 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 24 ноябре
№ 78-ТРЗ